# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Наркотик чараларның яисә психотроп матдәләрнең әйләнешенә һәм кулланылышына бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында**

Әлеге Закон гражданнарның сәламәтлеген саклау, дәүләт һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү максатларында наркотик чараларның яисә психотроп матдәләрнең әйләнешенә һәм кулланылышына бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылыкны билгели.

1 статья. Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр:

Наркотик чаралар, психотроп матдәләр булдыру - аларны сатып алу, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт яки бурычны кайтару өчен, үзара исәп-хисап ясау чарасы буларак алу, башка товарларга һәм әйберләргә алмашу, табылганны үзләштерү, наркотиклы кыргый үсемлекләрне яки аларның өлешләрен җыю (шул исәптән, әгәр бу үсемлекләр чәчеп үстерелгән булмаса, авыл хуҗалыгы һәм башка предприятиеләрнең җир кишәрлекләрендә, шулай ук гражданнарның җир кишәрлекләрендә җыю), наркотиклы үсемлекләрне урып-җыю төгәлләнгәннән соң саклаусыз калган кырлардан аның калдыкларын җыю һәм башка ысуллар белән булдыру;

Наркотик чараларны, психотроп матдәләрне саклау - наркотик чараларның яки психотроп матдәләрнең гаепле кеше карамагында (әгәр аны кайтартуга бәйле булмаса, үзе белән, бина эчендә, яшерен урында яки башка урыннарда) фактта булуына бәйле теләсә нинди аңлы гамәлләр. Саклаган өчен җаваплылык саклау дәвамлылыгына бәйле түгел.

Наркотик чараларны яки психотроп матдәләрне законсыз куллану - наркотик чараларны яки психотроп матдәләрне табиб билгеләмәгән килеш куллану.

Наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең таралуына ярдәм итүче эшчәнлек – юридик һәм физик затларның сәүдә, көнкүреш хезмәте күрсәтү, халыкка түләүле хезмәт күрсәтү, массакүләм һәм клуб тамашалары, күңел ачу һәм спорт гамәлләре

үткәрү өлкәсендәге хуҗалык эшчәнлеге, шулай ук эшчәнлекнең аны башкару барышында наркотик чараларны һәм психотроп матдәләрне таратуны һәм куллануны булдырмаучы чаралар күрелми торган башка төрләре.

Уку-укыту һәм башка мәгариф учреждениеләре тирәсендәге территория - теләсә кайсы милек рәвешендәге мәктәпкәчә учреждениеләргә, урта, махсус, һөнәри белем бирү һәм югары уку йортларына караган бинадардан 200 метрга кадәр арадагы территория;

2 статья. Наркотик чараларны яки психотроп матдәләрне законсыз куллану

1. Наркотик чараларны яки психотроп матдәләрне законсыз кулланган өчен-

хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

2. Административ җәза чаралары кулланылганнан соң бер ел эчендә шул ук гамәлләр кабатланса -

хезмәт өчен түләүнең биштән алып ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

3. Әлеге статьяның беренче һәм икенче өлешләрендә каралган, уку-укыту һәм башка мәгариф учреждениеләре тирәсендәге территориядә башкарылган гамәлләр өчен -

хезмәт өчен түләүнең уннан алып егерме минималь күләменә кадәр штраф салына йә ун тәүлеккә кадәр административ кулга алу карала.

3 статья. Наркотик чараларны яки психотроп матдәләрне аз күләмдә законсыз булдыру яисә саклау

1. Наркотик чараларны яисә психотроп матдәләрне аз күләмдә законсыз булдырган яки сату максатын куймыйча саклаган өчен -

хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

2. Административ җәза бирелгәннән соң бер ел вакыт эчендә шул ук гамәлләрне кабат яки уку-укыту һәм башка мәгариф учреждениеләре территориясендә башкарган өчен -

хезмәт өчен түләүнең уннан алып егерме минималь күләменә кадәр штраф салына яисә ун тәүлеккә кадәр административ кулга алу карала.

Искәрмә: әлеге Законның 2 һәм 3 статьяларында каралган хокук бозуларны башкарган затлар наркотик чараларны яисә психотроп матдәләрне ихтыярый тапшырсалар, наркотик чараларның яисә психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә бәйле хокук бозуларны

һәм җинаятьләрне ачуда актив ярдәм итсәләр, хокук бозган өчен җаваплылыктан азат ителәләр.

Махсус медицина учреждениеләренә наркоманиядән дәвалану буенча ихтыярый мөрәҗәгать иткән затлар, бу Законның 2 һәм 3 статьяларында каралган хокук бозулар өчен җаваплылыктан азат ителәләр.

4 статья. Канда һәм бүтән биологик мохитләрдә наркотик чараларның булуын медицина таныклавыннан баш тарту

Эчке эшләр, прокуратура, суд һәм сәламәтлек саклау органнарының күрсәтмәләре булып та, махсуслаштырылган медицина учреждениеләрендә канда һәм бүтән биологик мохитләрдә наркотик матдәләрнең булуын медицина таныклавыннан берничә мәртәбә баш тарткан өчен -

хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

5 статья. Наркотиклы үсемлекләрне юк итү чараларын күрмәү

1. Наркотиклы үсемлекләр үрчетү өчен махсус рөхсәткә ия булмаган гражданнар, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар карамагындагы җир кишәрлекләрендә наркотиклы үсемлекләрне юк итү чараларын күрмәгән өчен -

гражданнарга хезмәт өчен түләүнең ун минималь күләменә кадәр, урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең егерме минималь күләменә кадәр штраф салына.

2. Административ җәза бирелгәннән соң бер ел эчендә шул ук гамәлләрне кабатлаган өчен -

хезмәт өчен түләүнең уннан алып егерме биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

6 статья. Наркотик чаралар яисә психотроп матдәләр куллану өчен бина бирү

1. Наркотик чаралар яисә психотроп матдәләр куллану максатында бина биргән өчен -

хезмәт өчен түләүнең биштән алып ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

2. Шул ук гамәлләр уку-укыту һәм башка мәгариф учреждениеләре тирәсендәге территориядә кабатланса, йә наркотик чаралар яисә психотроп матдәләр куллануны оештырган, йә притоннар тоткан өчен элек хөкем ителгән зат шул ук гамәлләрне кабатласа, -

хезмәт өчен түләүнең уннан алып егерме биш минималь күләменә кадәр штраф салына йә унбиш тәүлеккә кадәр административ кулга алу карала.

7 статья. Наркотик чараларны яисә психотроп матдәләрне саклауга яки таратуга ирек бирмәүче чаралар күрелмәү

1. Хуҗалык эшчәнлеген башкарганда юридик затлар тарафыннан наркотик чараларны яисә психотроп матдәләрне саклауга яки таратуга ирек бирмәүче чараларны эчке эшләр органы тиешле күрсәтмә биргәннән соң ел дәвамында кабат күрмәгән өчен -

урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең уннан алып егерме биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

2. Шул ук гамәлләр берничә мәртәбә йә уку-укыту һәм башка мәгариф учреждениеләре тирәсендәге территориядә кабатланса, -

урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең егерме биштән алып кырык минималь күләменә кадәр штраф салына.

8 статья. Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карауга вәкаләтле органнар

1. Әлеге Законның 2 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләрендә, 3 статьяның беренче өлешендә, 4 һәм 5 статьяларда, шулай ук 6 статьяның беренче өлешендә каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр хокук бозылган урындагы эчке эшләр органнары башлыклары тарафыннан карала.

2. Әлеге Законның 2 статьясындагы өченче өлешендә, 3 статьясындагы икенче өлешендә, 6 статьясындагы икенче өлешендә, 7 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр административ хокук бозу урынындагы судлар тарафыннан карала.

9 статья. Административ хокук бозулар турындагы беркетмәләр

Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләр эчке эшләр органнарының вәкаләтле урындагы затлары тарафыннан төзелә.

10 статья. Штрафлар суммасын бүлү

Әлеге Законда каралган хокук бозулар өчен штрафлар суммасының 25 проценты Татарстан Республикасының республика бюджетына, 25 проценты - административ материаллар каралу урыны буенча шәһәрләр һәм районнар бюджетларына, 50 проценты -

Наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә каршы тору бюджеттан тыш дәүләт фондына җибәрелә.

11 статья. Йомгак нигезләмәләр

1. Наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә каршы тору бюджеттан тыш дәүләт фонды төзелгәнче әлеге Законда каралган хокук бозулар өчен штрафлар суммасының 50 проценты - Татарстан Республикасының республика бюджетына, 50 проценты административ материаллар каралу урыны буенча шәһәрләр һәм районнар бюджетларына җибәрелә.

2. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2473